РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ МИЧАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422055, Республика Татарстан, Сабинский район,
Село Старый Мичан , ул. Школьная, 12
тел. (84362) 42-3-31

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МИЧӘН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422055, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иске Мичэн авылы, Мэктэп урамы, 12 йорт
тел. (84362) 42-3-31

e-mail: mich.sab@tatar.ru

---

РЕШЕНИЕ КАРАР
25.03.2019 № 6

Биналарга, корылмаларга,
бүлмәләргә якын тирәдә
алкогольле продукцияне
ваклап сату рөхсәт ителми
торган урыннар турында

1995 елнын 22 ноябрендә 171номерлы Федераль законның «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга салу турында» 16 статьясы нигезендә,2012 елнын 27 декабрендә 1425 номерлы «Алкогольле продукцияне ваклап сатарга ярамый торган гражданнарның күпләп җыелу урыннарын һәм югары дәрәҗәдәге куркыныч чыганаклары урнашу урыннарын Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләү, шулай ук алкогольле продукцияне ваклап сатарга ярамый торган кайбер оешмалар һәм объектлар янындагы чикләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү турында» РФ Хөкүмәтенең Карары нигезендә, алкогольле продукцияне ваклап сату һәм алкогольле продукцияне ваклап сату тирә-юнь территорияләре чикләрен билгеләү буенча вәкаләтләрне тапшыру турында төзелгән килешү нигезендә, иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләрен исәпкә алып,Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Советы КАРАР итте:

1.1995 елның 22 ноябрендәге 171 номерлы Федераль законның «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга салу һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчү) чикләү турында» 16 статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасында күрсәтелгән биналарга, корылмаларга, бүлмәләргә якын территориядә алкогольле продукцияне ваклап сату 10 метр радиуста рөхсәт ителми.
2.Якын-тирә территория чикләрен исәпләү өчен өстәмә территория исәпләү тәртибе радиус буенча, отсчет нокталарыннан чыгып билгеләнә дип билгеләргә:

а) аерым территория – йомыш белән килүчеләр өчен алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмалар һәм объектлар (яки)

урнашкан аерымланган территориягә (алга таба – кагыйдәләр буенча) «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гражданнар күпләп җыелу урыннарын һәм югары куркыныч чыганаклары урнашу урыннарын билгеләү турында " 2012 елның 27 декабрендәге 1425 номерлы РФ Хөкүмәте Карары белән расланган Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмалар һәм объектлар чикләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү кагыйдәләренең 2 пунктында күрсәтелгән аерым территориягә шулай ук алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмалар һәм объектлар янындагы территорияләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан чикләрен билгеләү»;

б) Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгән оешмалар һәм (яки) объектлар урнашкан бинага (төзелешкә, корылмага) аерым территория булмаганда.

3.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге карар нигезендә күрсәтелгән Кагыйдәләрнең 2 пунктында һәр оешма һәм (яки) объект өчен якын-тирә территорияләр чикләрен схемасын эшләү һәм раслау турында.

4. Район чаралары үткәрү вакытында гражданнарның күпләп җыелу урыннарында алкогольле продукцияне ваклап сатуны Мичән авыл җирлеге Башкарма комитетының аерым карары белән регламентлана дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Саба районындагы территориаль бүлегенә, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Арча территориаль органына, Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча Эчке эшләр бүлегенә федераль законнарның үтәлешен һәм әлеге карарның үтәлешен тикшереп торырга тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Советының 2017 нче елның 1 нче декабрендә кабул ителгән 31 нче номерлы «Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга, бүлмәләргә якын-тирә мохит турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы, авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/michan адресы буенча урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Мичән авыл җирлеге башлыгы А.Ә.Гәрәев